ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д. 2А, д. Нижние Аты,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 2А йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

**Тел. (84366)50-7-35, факс (84366)50-7-35 E-mail: Sat.Ars@tatar.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**23 декабрь 2025 ел** **№21**

**Пиротехник эшләнмәләрдән файдалану
өчен рөхсәт ителгән урыннарны
билгеләү турында**

Яңа ел бәйрәм чаралары чорында гражданнарның гомере һәм сәламәтлеге иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне тәэмин итү максатларында, “Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм “Янгын куркынычсызлыгы турында”1993 елның 18 маендагы 1866-XXII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында” 22 декабрь 2025 елнын № 1121 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алып, Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Биеклеге 50 метрдан артык булган салютлар һәм фейерверклар үткәргәндә, шулай ук җир яисә су өслегенә һава юллары полосаларын проекцияләү чикләрендә, салютлар һәм фейерверклар биеклегенә бәйсез рәвештә, һава киңлегеннән файдалану Россия Федерациясе Һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасының оператив органы рөхсәте белән гамәлгә ашырыла (алга таба - Вәкаләтле орган).

Фейерверк уздыру өчен вәкаләтле органнан рөхсәт алырга кирәк. Язма рөхсәттән башка муниципаль берәмлек территориясендә фейерверк уздыру тыела.”

2. Пиротехник эшләнмәләрдән файдалану өчен рөхсәт ителгән урыннар дип түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Урта Аты авылы купере янында , торак пункттан 300 метр ераклыкта;
- Түбән Аты авылы төньяк юнәлешендәге басу ,торак пункттан 300 метр ераклыкта;

- Кылычы авылы төньяк-көнчыгыш юнәлештә, торак пункттан 300 метр ераклыкта

- Урта Сәрдә авылы төньяк -көнчыгыш юнәлештә, торак пункттан 300 метр ераклыкта

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм Урта Аты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР, Арча районы, Тубән Аты авылы, Үзәк ур., 2а, ТР, Арча районы, Урта Сәрдә авылы,Үзәк ур., 70А йорт

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Урта Аты авыл җирлеге
башлыгы Р.Х.Батталова

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СРЕДНЕАТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609009770